КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 20 сентябрь г.Казань № 885

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга юридик зат, шәхси эшмәкәр йә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 май, 431 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга юридик зат, шәхси эшмәкәр йә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 май, 431 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 май, 311 нче; 2017 ел, 6 декабрь, 938 нче; 2019 ел, 21 сентябрь, 863 нче; 2020 ел, 3 август, 645 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә

куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибен (карарга теркәлә) расларга.»;

2 пунктта «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга юридик зат, шәхси эшмәкәр йә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә» сүзләрен «Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә» сүзләренә алмаштырырга;

$2^1$ пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга юридик зат, шәхси эшмәкәр йә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибе»;

1.1 пунктта «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга юридик зат, шәхси эшмәкәр йә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә» сүзләрен «Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктта «юридик зат, индивидуаль эшмәкәр яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда» сүзләрен «индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик

затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда» сүзләренә алмаштырырга;

1.2[1] пунктта «юридик зат, индивидуаль эшмәкәр яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда» сүзләрен «индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда» сүзләренә алмаштырырга;

1.2[2] пунктта «юридик зат, индивидуаль эшмәкәр яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда» сүзләрен «индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктта өченче абзацта «юридик зат, индивидуаль эшмәкәр яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда» сүзләрен «индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Документларны әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме 18 яше тулган һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Эшсез гражданнарның үзмәшгульлегенә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (эшсез дип билгеләнгән тәртиптә танылган гражданнарга һәм эшсез дип билгеләнгән тәртиптә танылган, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри укуда булган һәм өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга аларны юридик зат, индивидуаль эшмәкәр яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы буларак дәүләт теркәвенә алганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алганда документларны әзерләү өчен бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтүне кертеп) федераль дәүләт стандартын раслау турында» 2013 елның 24 декабрендәге 773н номерлы боерыгы белән расланган Эшсез гражданнарның үзмәшгульлегенә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (эшсез дип билгеләнгән тәртиптә танылган гражданнарга һәм эшсез дип билгеләнгән тәртиптә танылган, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри укуда булган һәм өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга аларны юридик зат, индивидуаль эшмәкәр яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы буларак дәүләт теркәвенә алганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алганда документларны әзерләү өчен бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтүне кертеп) федераль дәүләт стандартының 17 пунктында каралган тәртиптә эшсез гражданнарның эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү нәтиҗәләре буенча индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алу, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алу, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алу, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә кую юлы белән эшмәкәрлек

эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында тәкъдимнамәләрдән гыйбарәт бәяләмә алган эшсез гражданнарга күрсәтелә.»;

2.5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Индивидуаль эшмәкәр яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы буларак, шулай ук физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә кую юлы белән эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруны планлаштыручы эшсез граждан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә, бизнес-планын теркәп, эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү турында гариза бирә.»;

түбәндәге эчтәлекле $2.13^1$ пункт өстәргә:

«$2.13^1$. Физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә кую юлы белән теркәлгән гражданның шәхси (банк) счетына эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәмен күчерү әлеге граждан тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәмен күчерү турында түбәндәге документлар белән гариза бирелгәндә башкарыла:

Федераль салым хезмәтенең һөнәри керемгә салым түләүчеләр өчен рәсми мобиль кушымтасы – «Минем салым» кушымтасында формалаштырылган, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә кую юлы белән теркәүгә алуны раслый торган белешмә кәгазе;

гражданның бизнес-планын тормышка ашыруга үз акчасы булуын раслый торган белешмә кәгазе (өземтә), шәхси (банк) счетыннан банк өземтәсе яисә, саклык кенәгәсенең төп нөсхәсен күрсәтеп (әгәр күчермәсе нотариус тарафыннан таныкланмаган булса), саклык кенәгәсе күчермәсе яки бизнес-планын тормышка ашыру өчен җиһаз, материаллар, инструментлар һәм башка мөлкәтне сатып алуны яисә аларның булуын раслый торган документлар.»;

2.17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.17. Бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтүнең нәтиҗәсе – индивидуаль эшмәкәр буларак теркәүгә алган, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алган, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алган, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйган көннән кимендә 12 ай эчендә бизнес-план нигезендә эшмәкәрлек эшчәнлеген алып бару.»;

3.6 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«индивидуаль эшмәкәр яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы буларак дәүләт теркәвенә алган, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйган көннән кимендә бер елдан азрак була алмаган бизнес-планны тормышка ашыру өчен шартнамәдә билгеләнгән срок чыкканга кадәр индивидуаль эшмәкәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы буларак эшчәнлекне туктату, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәптән төшү;»;

әлеге Тәртипкә кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибенә кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 20 сентябрь, 885 нче
карары редакциясендә)

Форма

Индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү нәтиҗәсенә ирешү турында
хисап

| Т/с | Нәтиҗәнең исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификациясе буенча үлчәү берәмлеге | | Нәтиҗәнең план буенча мәгънәсе | Хисап датасы хәленә карата нәтиҗәнең ирешелгән мәгънәсе | Нәтиҗәнең план буенча мәгънәсен үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | исеме | коды | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. | Индивидуаль эшмәкәр буларак теркәүгә алган, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алган, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алган, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйган көннән кимендә 12 ай эчендә бизнес-план нигезендә эшмәкәрлек эшчәнлеген алып бару | ай | 366 | 12 | | | |

_______________________________ (җитәкченең вазыйфасы)

___________________________________________________ (җитәкченең, индивидуаль эшмәкәрнең имзасы, Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда)

М.У. (булганда)

Баш бухгалтер ____________________ (имзасы) _______________________________________________ (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда)

20__ ел, «___» ___________

_____________________________